**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 7 октябрь № 721

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2016 ел, 1 июнь, 367 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2016 ел, 1 июнь, 367 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулага «тормышка ашыру максатында» сүзләренә кадәр «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлтелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан 2016 елда субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2016 ел, 29 февраль, 155 нче карарын» сүзләрен өстәргә»;

1 пунктның икенче абзацына «2016 елда» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала;

әлеге карар белән расланган субсидияләр бирү тәртибен куллану буенча аңлатуларны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны бергә финанслауга Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибендә:

исеменә «2016 елда» сүзләрен өстәргә;

1 пунктка «Татарстан Республикасы хезмәт базарында» сүзләренә кадәр «2016 елда» сүзләрен өстәргә;

4 – 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлыкка финанслауның чик күләмнәрен җиткерү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитларын һәм кысаларында федераль бюджеттан субсидия күчерү гамәлгә ашырыла торган федераль бюджеттан финанслауның чик күләмнәрен җиткерү турында мәгълүматны алган көннән соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка финанслауның чик күләмнәрен Министрлыкка җиткерүгә чыгым җәдвалын тапшыра.

6. Министрлык счетына финанслауның чик күләмнәрен җиткергән көннән соң җиде эш көне эчендә Министрлык Казначылыкка Министрлык билгеләгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре (алга таба – эш белән тәэмин итү үзәкләре) счетларына финанслауның чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым җәдвалын тапшыра.»;

әлеге карар белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында эштән чыгару куркынычы булган оешмалар хезмәткәрләрен, шулай ук ябылу яисә хезмәткәрләр саны яки штаты кыскару белән бәйле бүтән оешмалардан эштән чыгарылып даими эшкә кабул ителгән хезмәткәрләрне алга китеп һөнәри укыту яки стажировка оештыруга (шул исәптән башка җирлектә) субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктта «Катнашу хокукы» сүзләрен «Катнашу өчен җибәрелү хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта формуладан соң 12 пунктта «оешма буенча бер айга бер хезмәткәрне укытуның уртача бәясе 1 кешегә 30 мең сумнан артмаска тиеш» сүзләрен «1 айга укуның исәпләнгән уртача бәясе – бер кешегә 30 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

16 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 2016 елда эш бирүчеләргә һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшкә алынган гражданнарның хезмәте өчен түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибендә «халыкны эш белән тәэмин итү үзәге җибәрүе буенча һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан _____ кеше санында гражданнарны эшкә урнаштырырга әзер» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан _____ кеше санында гражданнарны эшкә урнаштырырга әзер» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин